# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ, май, 2025 ел № 7

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

***1. Сау бул, сөекле бакчабыз, без мәктәпкә китәбез!***
***2. «Юный полиглот» бәйгесенең уңышлы нәтиҗәсе.***
***3. «Хезмәткә һәм оборонага әзер!»***
***4. «Җиңү алып килде язлар илебезгә»***

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**

Саубул, бакча!

30 нчы май көнне безнең бакчабызда мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының бакча белән саубуллашу кичәсе булып узды. Быел бакчабыздан 9 баланы: 5 кыз һәм 4 малайны мәктәпкә озаттык. Менә алар:

-Күп белергә тырышучы – Асхадуллина Илүзә;
-Иң ихтирамлы – Хөсәйнов Дилүс;
-Иң тырыш – Хөсәинова Ләйлә;
-Иң тәртипле – Хәйретдинов Әмир;
-Иң шаян – Гатауллина Алинә;
-Иң актив – Гарипов Азамат;
-Иң җаваплы – Закирова Мәдинә;
-Иң мөлаем – Гатауллина Айсинә;
-Иң тыйнак – Рахимов Инсаф.

Мәктәп ул – белем йорты. Бу йортны беренче тапкыр атлап керү – зур бәйрәм. Мәктәп ишеген ачып кергәч тә, ягымлы елмаеп, сезне укытучы апагыз каршы алыр. Ул сезне дөрес утырырга, китап-дәфтәрләрне ничек куярга кирәклеген, укырга, язарга өйрәтер. Җир, табигать серләрен аңларга ярдәм итәр. Ак юллар сезгә, балалар!!!

Кай арада зур үстегез,
Бик тиз үтте бу еллар.
Хушлашабыз сезнең белән,
Кадерле, нәни дуслар.












6-нчы май көнне Арчаның 7-нче номерлы балалар бакчасында “Юный полиглот” районкүләм бәйге булып узды. Быел ул Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган иде. Арча районы һәм авыллларыннан һәр ел әлеге бәйгедә бик күп балалар теләп чыгыш ясыйлар, бәйге чын дәрәҗәдә зур бер бәйрәм кебек уздырыла. Безнең балалар бакчасыннан бу конкурста быел мәктәпкә әзерлек төркеменнән Хөсәйнов Дилүс катнашты. Ул Бөек Җиңү темасына багышланган татар, рус, инглиз телендә чыгыш ясап, мактаулы 1-нче урынга лаек булды.

Алга таба да бу бәйгедә бездә тәрбияләнүче тырыш, акыллы, максатчан балалар катнашыр дип көтәбез.











Күптән түгел «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенрәсәй физкультура-спорт комплексы фестивале узды. Арча муниципаль районының мәктәпкәчә яшьтәге балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр өчен оештырылган әлеге фестивальдә бездә тәрбияләнүче Әсхәдуллина Илүзә һәм Хәйретдинов Әмир катнашып, дәрәҗәле 2-нче урын яуладылар һәм ГТО тамгалары белән бүләкләнделәр. Афәрин!







Ярышлар кысаларында командаларга комплексы сынауларны чиратлашып үтәргә кирәк иде. Барлык катнашучылар да 30 метрга йөгерү кебек сынауларда үз нәтиҗәләрен күрсәттеләр. Балалар биремнәрне түземлек, җитезлек һәм өлгерлек күрсәтеп үтәделәр. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, мондый чараларда катнашу балаларның һәм өлкәннәрнең физик культурасына һәм сәламәт яшәү рәвешенә кызыксыну арттыра. ГТО нормаларын әзерләү һәм үтәүдә катнашу балаларның сәламәтлеген ныгыту, ихтыяри сыйфатлар тәрбияләү, җиңүгә омтылуны һәм үз көченә ышанычны үстерү өчен шартлар тудырырга гына түгел, ә аларны якынайтырга да мөмкинлек бирә.





9 Май - Җиңү көне - безнең һәрберебез өчен изге бәйрәм һәм без, илебезнең бүгенге гражданнары, Җиңү турында хәтерне киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш. Мөндеш балалар бакчасында Бөек Җиңү көненә багышланган чаралар елдан-ел үткәрелә һәм быел да искәрмә түгел.

Бөек Ватан сугышы турында белемнәр формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үз илебезнең тарихы турында белемнәрен арттыру, халкыбызның каһарманлыгы өчен горурлык хисе тәрбияләү, армия белән тотрыклы кызыксыну тәрбияләү максатыннан тәрбия сәгатьләре, “Җиңү авазы” исеме астында шигырь бәйгесе уздырылды. Бөек Ватан сугышында катнашучы бабаларыбызның фотосурәтләре белән “Үлемсез полк” һәм махсус хәрби операциядә катнашкан авылдаш егетләребез хөрмәтенә стенд булдырылды.

Бу - балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең дәү бабалары батырлыгын, фашизмны җиңүгә керткән бәһа биргесез өлешен хәтердә тоту билгесе.









